**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНы СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2019ел, 18 марта № 207

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2012 елның 6 февралендәге 57 номерлы "Күп балалы гаиләләргә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, индивидуаль торак төзелеше, дача төзелеше, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәрен билгеләү турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2012 елның 6 февралендәге 57 номерлы "Күп балалы гаиләләргә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, индивидуаль торак төзелеше, дача төзелеше, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәрен билгеләү турында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга бушлай бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) күләмен билгеләү турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«1.Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга шәхси торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт яны җир участогы), бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) күләмен билгеләргә»;

дүртенче абзац төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Элек бирелгән җир кишәрлегендә урнашкан торак йорт милкендә, әгәр федераль закон нигезендә мондый җир кишәрлеге шәхси милеккә бирелергә мөмкин булмаса, элек бирелгән җир кишәрлекләре күләме, ләкин 0,20 гектардан артык түгел».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башлыгы урынбасары Л.Т.Хантимировка йөкләргә.

**Апас муниципаль районы Башлыгы –**
**Апас муниципаль район Советы рәисе Р.Н. Заһидуллин**